Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№28 (121)
9 октябрь 2014 ел



Влад Михневский фотосы

# Бирегез мәйдан! БЕРЕНЧЕЛӘРГӘ!!!

6-16 октябрь көннәрендә уку йортыбызда елдагыча «Беренче курслар» фестивале узачак. Быел институт һәм факультетлардан барлыгы 18 команда катнашачак. Яңа гына студент булган яшь талантлар иҗади осталыкларын күрсәтәчәк, җыр һәм биюгә һәвәслекләрен күрсәтәчәк. Конкурс нәтиҗәләре буенча иң яхшы чыгыш ясаучылар лауреат һәм җиңүче грамоталары белән бүләкләнәчәк. Тантаналы рәвештә нәтиҗәләр ясау 25 октябрь көнне «Уникс» концертлар залында Гала-концертта башкарылачак.

• Атна ачышы

# Россиядә беренче үзәк – бездә!

**Рәдифә ШАФИКОВА,**
Матбугат үзәге

7 октябрьдә Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбендә Cisco инновацияләр үзәген ачу тантанасы булды. Чарада ТР президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.


Матбугат үзәге фотосы

Мондый үзәк ачылу – Татарстан Республикасы һәм Cisco компаниясенең киң масштаблы хезмәттәшлеге нәтиҗәсе. Исегезгә төшерәбез, меморандум кысаларында безнең республика һәм берничә юнәлештә эшли торган Америка транснациональ компаниясе арасында хезмәттәшлек итү планлаштырылган иде. Шуларның берсе – Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе базасында Cisco инновацияләр үзәген булдыру. Бу – Россиядә югары уку йорты базасында ачылган мондый дәрәҗәдәге беренче проект.

Cisco Инновацияләр үзәгенең максаты – Россия һәм халыкара базарда бизнес һәм дәүләт тарафыннан таләп ителә торган инновацияле фәнни-гамәли эшләнмәләрне тормышка ашыру; вуз хезмәткәрләрен, студентларны, аспирантларны, ТР икътисадының реаль секторы предприятиеләре вәкилләрен җәлеп итеп, импортны алыштыру технологияләрен һәм хезмәт күрсәтүне үстерү. Инновацияләр үзәге нигезендә элемтә системаларын проектлау өлкәсендә, навигация системалары һәм перспективалы антенна техникасы өлкәсендә эшләр алып барылачак.

«Хәзерге көндә шәһәрләр бик тиз үсә, тормышыбыз тиз үзгәрә, шуңа күрә шәһәрләр белән дә, йортлар беләндә, автомобильләр белән дә идарә итәрдәй яңа технологияләр кертергә кирәк. Мондый эшләнмәләр Cisco инновацияләр үзәгендә башкарылыр, дип уйлыйм. Cisco технологияләрне алар заказы буенча эшләргә тәкъдим итә. Димәк, биредә эшләнәчәк, шунда ук я республикабызда, я Россиядә, я дөньяда тормышка ашырылачак», диде ректор Илшат Гафуров.

Күп кенә проектлар уку йортыбызның Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбенең автоном робот-техник системалар кафедрасы базасында, Дмитрий Чикрин җитәкчелегендә алып барылачак. Cisco һәм Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбенең автоном робот-техник системалар кафедрасы планнарында күп проектлар өстендә эшләү. Бүгенге чара кысаларында Татарстан Президентына шулар хакында сөйләделәр дә. Республика башлыгына шулай ук лаборатор җиһазларны һәм кайбер эшләнмәләрне дә күрсәттеләр.

Әйтик, «Акыллы шәһәр» концепциясе кысаларында интеллектуаль энергетика һәм ТКХ өлкәләрендәге чишелешләрне тормышка ашыру. «Акыллы автобус» проекты юл хәрәкәте куркынычсызлыгының автомат күчмә контроль системасын эшләүне һәм шәһәр автомобиль трафигын һәм парковка структурасын оптимальләштерүне күздә тота.

Cisco инновацияләр үзәген ачу кысаларында ике документ имзаланды. ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов белән Cisco компаниясенең Европа, Якын Көнчыгыш, Африка, Россия һәм БДБдагы президенты Крис Дедикот Cisco компаниясе һәм Татарстан Республикасы арасында хезмәттәшлек буенча юл картасына кул куйдылар. Моннан тыш, И.Гафуров белән К.Дедикот КФУ һәм Cisco арасында хезмәттәшлек буенча ниятләр турында килешү имзалады. Мондый технологик белем бирү инициативалары безнең өчен бик мөһим. Без юкка гына инфраструктур инновацияләрне Казанда үстермибез. Шушы өлкә буенча Татарстан башкаласы алып торган лидерлык Россия территориясе өчен уникаль», дип ассызыклады Крис Дедикот.

• Халыкара мөнәсәбәтләр

# «Контактлы зона» булдырылды!

**Дания ФАТЫЙХОВА**

Октябрьнең беренче көннәрендә Азәрбайҗан башкаласында IV Халыкара Баку гуманитар форумы уздырылды.

Халыкара Баку гуманитар форумы – дөньяви берләшмәнең сәясәт, фән һәм мәдәни элитасы булган атаклы кешеләр, шул исәптән дәүләт эшлеклеләре, Нобель премиясе лауреатлары да катнашкан, ел саен уздырыла торган чара. Аның максаты булып барлык кешеклек дөньясын борчый торган глобаль характердагы киң сораулар спектрына караган мәсьәләләрнең чишү юлларын эзләү, фикер алышу тора. Бу исә, үз чиратында, гади кешене генә түгел, дәүләт лидерларын да борчыган архиактуаль темаларны яңгыратыр өчен арена әзерләү дигән сүз. Форумның нәтиҗәсе халыкара оешма, ил җитәкчеләре һәм аерым индивидларга тәкъдим һәм чакыру буларак гәүдәләнде.




Гомумән, чарада 800дән артык кеше катнашты. Алар арасында Нобель премиясенең 14 лауреаты да бар иде. Форумның эшчәнлегендә Азәрбайҗанның Фәннәр милли академиясе һәм оештыру комитеты чакыруы буенча КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты профессоры Альберт Борһанов та катнашты. Биредә ул «Евразиянең мәдәни-икътисади традицияләренең контактлы зоналары һәм ретрансляторы буларак Сырдарья-Амур һәм Идел-Урал төбәкләре (Борынгы заман һәм Урта гасырларда тарихи-мәдәни элемтә һәм контаклы зоналарны өйрәнү мәсьәләләре» темасына чыгыш ясады. «Мин бу конференциядән үзем өчен бик күп яңалык алдым. 200гә якын кызыклы кешеләр белән таныштым. Таныш йөзләрне дә очраттым. Галимнәр белән Татарстан, Казан турында да сөйләшеп алырга өлгердек. Мәсәлән, Нидерланд вәкилләре безнең республика белән бик кызыксынды», – дип уртаклашты хис-кичерешләре белән А.Борһанов.

Конференциядә катнашучылар өчен экскурсияләр дә оештырганнар. Кунакларны җирле төбәкнең төрле урыннарына, шәһәрләренә алып барганнар. Музей, борынгы зират һәм крепостьлар, изге мәгарә h.б. истәлекле урыннарын күрсәткәннәр. А.Борһанов анда якташларын – татарларны да очраткан. «Кемнеңдер әнисе – татар, кемдер үзе татар иде», – дип искә ала ул.

• Искә алу


Влад Михеевский фотосы

7 октябрь көнне КФУ Тарихы музеенда күренекле галим-геометр Александр Петрович Норденны искә алу кичәсе узды. Ярты гасырга якын Казанда яшәп, актив фәнни-педагогик эшчәнлек алып барган киңкырлы шәхескә быел 110 яшь тулды.

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

# В.Чугунов: «Минем өчен бөек лектор ул...»

Александр Норденның Казан университеты белән бәйлелеген туган елыннан ук әйтеп була, чөнки ул 1904 елда, ягъни уку йортының 100 еллыгында, Саратов шәһәрендә укытучылар гаиләсендә туа.

Бөек геометрның биографиясе, фәнни эшчәнлеге турында аның укучылары, хәзер исә Математика һәм механика институты доцентлары В.Е.Фомин белән В.В.Шурыгин сөйләделәр. Мәркәзебезгә ул 1945 елда килә һәм ректор К.П.Ситников тәкъдиме белән Казан университетының геометрия кафедрасын җитәкли башлый. Биредә яшәү, эшләү чорында ул, иң беренче чиратта, оста лектор буларак танылa. «А.П.Норден – бөек лектор. Ул безгә дифференциаль геометрия курсыннан лекцияләр укыды. Аның лекцияләре шундый кызыклы һәм эчтәлекле иде ки, без, берсен дә калдырмыйча, зур теләк белән йөрдек. Лекцияне ике өлешкә бүлеп, шулар арасында пауза ясап, теләсә нинди дөньяви темага әңгәмә корырга да мөмкин иде ул», – дип искә алды Математика һәм механика институты директоры В.А.Чугунов.

Чарада галимнең туганнары, чордашлары да катнашты. А.П.Норденның оныгы бабасының күбебез белмәгән кызыксынулары турында сөйләде: «Геометриядән кала, бабам поэзия, шигырьләр язу белән мавыга иде. (Бабасының бер шигырен дә сөйләде – И.В.). Классик музыка тыңларга, саф һавада йөрергә яратты, тарих белән кызыксынды». Физика институты профессоры А.В.Әминова болай дип искә ала: «А.П.Норденны беренче тапкыр Кремль урамы буйлап барганда күрдем. Ул вакытта мин студент идем әле. Мин аны башкаларга бөтенләй охшамаган шәхес итеп күзалладым. Һәм шулай булып чыкты да. Кызганыч, безгә ул лекцияләр укымады, ләкин киң мәгънәдә мин аны үземнең укытучым дип саныйм».

Казан университеты диварларында, укыту эшчәнлеге белән беррәттән, ул фәнни эш белән дә мавыга: бик күп, хәтта чит илләрдә танылу алган китаплар, мәкаләләр, монографияләр яза. А.П.Норден Н.И.Лобачевский идеяләрен үстерү һәм популярлаштыру эшен дәвам иттерә. Аның инициативасы буенча, Казан университетында зур фәнни чаралар уза. Актив фәнни-педагогик, җәмәгать эшчәнлеге ТАССР һәм РСФСРның лаеклы фән эшлеклесе исеме белән бәяләнә. Шулай ук ул, беренчеләрдән берсе буларак, КДУ тарафыннан билгеләнгән Н.И.Лобачевский исемендәге медаль иясе дә.

Университетыбыз тарихында тирән эз калдырган, танылган галим турында чыгыш ясаучылар күп булды: Һәркайсы аны хөрмәтләп, сагынып искә алды. Кичә, чараның сәбәпчесе яратканча, музыкантлар төркеменең классик музыка уйнавы белән тәмамланды.

Белем баскычлары

# Мәктәп укучылары – студентлар

Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА, доцент

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында 2012 елның 30 мартында Кече Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты эшли башлаган иде. 2 октябрь көнне Кече институт өченче уку елын башлап җибәрде.

Кече Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты үз эченә рус теле һәм әдәбияты, чит телләр факультеты, татар теле һәм әдәбияты факультетларын һәм сәнгать мәктәбен берләштерә. Анда 7 сыйныфтан алып, 11 сыйныфка кадәрге укучылар шөгыльләнә. Атнаның дүшәмбе көнендә Кече институт студентлары (алар әле укучы гына булсалар да, студент дип йөртеләләр) сәнгать мәктәбендә шөгыльләнә, пәнҗешәмбе – чит телләр факультетына йөри, җомга – рус теле һәм әдәбияты белән шөгыльләнә.

Һәр атнаның чәршәмбе көнендә татар теле һәм әдәбияты факультеты студентлары төрле дәресләр тыңлый. Көндезге бүлеккә Казанның 11, 14, 12, 17, 27 гимназияләреннән талантлы, татар теле һәм әдәбиятына гашыйк балалар йөри. Айның беренче чәршәмбесе – ана теле дәресе. Студентларыбыз өчен дәресләрне профессорлар, доцентлар үткәрә.



Безнең бүлек Язучылар берлеге, газитжурналлар, гомумән, татар дөньясы белән тыгыз элемтәдә. Быел татар теле, әдәбияты һәм журналистика белгечлеге ачылды. Шуны күздә тотып, Кече институтта «Яшь тәнкыйтьче мәктәбе» оештырылган иде. Һәр айның икенче чәршәмбесендә аны «Ялкын» журналының мөхәррире, кайчандыр безнең факультетны тәмамлаган Й.Миңнуллина үткәрә. Быел бу остаханә «Ялкын» журналының редакция бүлмәсендә үтәчәк.

Ә өченче чәршәмбе ул – әдәби иҗат берләшмәсе атнасы. Студентларыбыз «Әллүки» иҗат берләшмәсендә танылган язучы, КФУ доценты Халисә Кузьминадан (Ширмәннән), безнең бүлектә белем алучы яшь шагыйрә һәм прозаиклардан әдәби әсәр язу серләренә өйрәнәләр. Кече институт студентларына татар дөньясында танылган шәхесләребез белән танышу, аралашу, шул даирәдә кайный башлау мөмкинлеген дә киңәйтергә исәп тотабыз. Факультет һәр иҗади балага танылу мөмкинлеген ачарга тырыша.

Кече институтның татар теле һәм әдәбияты факультеты алга карап яши. Узган елларда биредә белем алган талантлы укучыларның күбесе бүген Зур институтта белем ала.

Әлеге структураны булдыру Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, профессор Р.Җамалетдинов идеясе була. Шунда ук бу фикерне хуплаучы энтузиастлар командасы җыела. «Әлбәттә, кече институт барлыкка килгәннән бирле, команданың составы шактый үзгәрде. Бу – котылгысыз күренеш. Мисал өчен, татар теле һәм әдәбияты факультеты деканы Гөлфия Расиловна безнең өчен, чын мәгънәсендә, табыш булды. Ул – шулкадәр актив, эшчәнлеге һәм эшен чынлап яратучы кеше. Яисә сәнгать һәм дизайн факультеты җитәкчесе Мәдинә Мәхмүтовнаны алыйк. Ул да бик иҗади, талантлы һәм укучыларны үзенә җәлеп итә. Башка деканнар да алардан ким түгел!

Һәр елны уку программасына үзгәрешләр кертелә. Бу нинди балалар килүгә һәм аларның санына бәйле рәвештә башкарыла. Без алар өчен кызыклы булган белемнәрне бирергә тырышабыз. Шуңа күрә планнарны да бер айга гына төзибез», – дип ассызыклый Кече Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты җитәкчесе Татьяна Бычкова.

Университет күләмендә мондый структура бары 2 институтта: Филология һәм мәдәниятара багланышлар һәм А.М.Бутлеров исемендәге химия институты составында бар. Әмма, химиялеләрдән аермалы буларак, кече филологларның укулары түлисенча бушлай алып барыла.

Хәйрия эше

Хуҗасыз хайваннар йортына күптән барасым килеп йөри иде, әмма я вакыт, я тәвәккәллек җитмәде. Һәм менә, ниһаять, күптәнге ниятем чынга ашты. Шушы көннәрдә Универсиада авылы студентлары ассоциациясе оештырган хәйрия акциясендә мин дә катнаштым, кече дусларыбыз янына кунакка бардым.

Гөлнара ШӘРӘФЕТДИНОВА

# Өч сүз җитә...

«Сүз белән кызганганчы, кечкенә генә булса да ярдәм күрсәтү күпкә яхшырак» девизы астында уздырылган акциядә һәртөрле кертем дә ирекле иде. Волонтер һәм оештыручылар 58635 сум һәм 2 кытай юане туплаганнан соң, без, күмәкләшеп, Биектау районында урнашкан «Зоозабота» йортына юл тоттык. Ул инде бер ел буе Казандагы хуҗасыз хайваннарга ярдәм итә. Мин, журналист буларак, волонтерлар командасына кушылдым, чөнки мондый форсатны кулдан ычкындыру акылга сыймас иде.

Безне «Зоозабота»ның рәисе, бик мөлаем хатын – Лариса ханым каршы алды. Аның сүзләренчә, аларга бу кадәр булышучының инде күптәннән килгәне юк икән.

Әлеге приютны 3 сүз белән тасвирласак, ул: чисталык, ачык йөз һәм ярату булыр иде. «Зоозабота» хезмәткәрләренең генә түгел, ә биргә ярдәм итү теләге белән килгән һәркемнең чиста нияте күренеп тора. Якты йөз: приютта һәр ишек тә ачык, телүгән вакытта песи һәм этләр янына кереп була. Иң мөһиме, үзеннән соң вольерларны ябарга онытмаска. Һәм ярату! Кешеләргә һәм үз эшләренә карата мәхәббәт хисе.

«Зоозабота» һәр төрле ярдәмне дә кабул итә. Мисал өчен, Универсиада авылы студентлары ассоциациясе, материаль ярдәм кертеп кенә калмады, питомникның түбәсен ябарга булышты, яңа вольерлар төзү өчен территорияләрне чистартты. Биредә, безнең белән бергә, шулай ук ярдәм итәргә теләүчеләр эшләде. Аларның кайберләре укудан соң, кайсыларыдыр эштән соң килгәннәр. Мисал өчен, анда Эвелина исемле кыз бар иде. Ул атна саен Казанның питомникларына барып булыша һәм бер эштән дә курыкмый икән.

«Без инде берничә ел рәттән шундый масштаблы хәйрия акцияләрен уздырабыз», – дип ассызыклады Универсиада авылы студентлары ассоциациясе рәисе Адина Кульмасова.

«Зоозабота» хезмәткәрләре Лариса, Вера һәм аның ире Универсиада авылы командасын күп рәхмәт һәм җылы сүзләр белән озатып калды. Без исә, үз чиратыбызда, әлеге рәхмәт сүзләрен сезгә җиткерәбез, дусларыбыз! Әлеге ситуациядә битараф калмаганыгыз өчен рәхмәт! Хәзер сезнең күңелегез, минеке кебек үк, тыныч һәм канәгатьтер дип уйлыйм.





*Приютта 13 песи һәм 27 эт яши. Аларның һәрберсенең дә язмышы бер: ябыгып һәм йоннары коелып беткән бичараларны чүплекләрдән табып алганнар. Әмма сез аларның приют территориясендә нинди купшы һәм канәгать булуларын күрсәгез иде! Алар барысы да чиста, тәрбияләнгән, аларны гел яратасы гына килеп тора.*

*Никита Тохтасинов фотолары*

Укытучылар көне

Укытучылар көне бер көн генә билгеләп үтелми. Без остазларыбыз алдында һәр көн, һәр сәгать бурычлы. Редакциябезгә шул уңайдан һәрдаим хатлар килеп тора. Чираттагысын сезнең игътибарга тәкъдим итмичә кала алмыйбыз.

## Хөрмәтле укытучым, кадерле укытучы-остазларым минем!

*Сезнең һәрберегезне ихлас күңелемнән матур һөнәри бәйрәмегез белән котлыйм!!!*

*Тормыш сукмагының аерым бер борылышында үз канаты астына алган, төпле белем, тиешле тәрбия, тормыш тәҗрибәсе биргән мөгаллим-мөгаллимәләрем, мең рәхмәт сезгә!!!*

*Сез, мине онытканнар, искә алмыйлар дип тә уйлап куясыздыр. Бүгенге дөнья мәшәкатьләренә чумганнар, тормыш итәргә кирәк бит, дип шунда ук үзегездән үк сүз тидермисездер. Уку елларындагы кебек, Сез һәрчак безне акларга тырышасыз.*

*Әмма шулай да сез елның бер көнендә генә истә түгел... Һәрчак истә... һәрбарчагыз, һәрберегез, иң кадерле-якыннарыбыз!..*

*Балалар бакчасында каршы алган тәрбияче-укытучы, мәктәп бусагасын атлап керергә ярдәм иткән беренче укытучы, төрле фәннәр дөньясы белән таныштырган укытучылар, урта һөнәр иленә алып кергән мөгаллимнәр, югары белем йортларының остаз-галимнәре... барыгыз да истә...*

*Шәхсән мин кадерләп, хөрмәт итеп, сагынып, рәхмәт әйтеп искә алам...*

*Шулай да Сез хаклыдыр: дөнья куып, онытылып киткән чаклар була, әмма дә ләкин озакка түгел. Көн дәвамында берегез генә булса да искә төшми калмыйсыз... Күп очракта рәхмәтемне әйтеп уйлап куйсам, кайчак сездән аңламаучылык-шөбһә белдерүебез өчен оялып, кичерүегезне сорыйм. Кылган яхшылыгыгыз, авыр чакта терәк булуыгыз, башка сыймаслык кыланышларыбызны аңларга тырышуыгыз, чиксез сабырлыктүземлегез, һәрберебезне Кеше итеп күрергә, тәрбияләргә омтылуыгыз, тормыш юлыбызда югалып калмыйча, үз урыныбызны табуыбызга өметләнеп, төпле белем бирүегез бәһасез!*

*Мактап, көч биреп торуыгыз, кырыс сүз, усал караш астында йөрәк әрнүен, җан сызлавын, күңел елавын яшереп, алга барырга өндәвегез безгә ышануыгыз булгандыр, мөгаен.*

*Кайчак сезнең мең яхшылык эшләп, бераз тәнкыйть сүзегез яки, безнең уйлавыбызча, хаксыз куелган билгеләр өчен озак үпкәләп йөргәнебезгә хәзер дә аклану-җаваплы таба алмыйм. Ул чакта да бит Сез зирәк укытучы-остазмөгаллимә булып кала алдыгыз!*

*Сез – чиксез ихтирамга лаек олуг затлар! Гомерегезне кеше баласына багышлап, аны үз нарасые итеп кабул итүче, сезнең кебек укытучылар тормыш юлыбызны бизәве үзе зур бәхет. Әле дә Сез (күбегез инде лаеклы ялда булуга карамастан) бала күңелен үсендерүче, төпле киңәш бирүче, туры юлга өндәүче!*

*Шулай озак еллар дәвамында һәрберегезнең кор тавышын ишетеп, җылы карашыгызны тоеп, һичшиксез, кирәкле киңәшләрегезгә ия булып, һәрбер уңышыбыз өчен шатланып, үз укучыбалагызга мактау сүзләрен бүләк итеп, ихластан сөенеп, яңаышдәгеләрнең сезгә карата олы ихтирамнарын, чиксез рәхмәтләрен сизеп, кадер-хөрмәттә яшәүләр насыйп булсын!!!*

***Чиксез ихтирам белән, укучыгыз Алсу Әшрәпова***

• Туган көн

# «Дарелфөнүн»ебезгә 3 яшь!!!



**6 ОКТЯБРЬ КӨННЕ БАРЫБЫЗ ДА ЯРАТЫП УКЫЙ, АТНА САЕН АНЫ ЗУР ТҮЗЕМСЕЗЛЕК БЕЛӘН КӨТЕП АЛА ТОРГАН «ДАРЕЛФӨНҮН»ЕБЕЗГӘ 3 ЯШЬ ТУЛДЫ! БИК КЕЧКЕНӘ БУЛСА ДА, УЛ ЗУРЛАР КЕБЕК ФИКЕР ЙӨРТӘ, КӨН КАДАГЫНДАГЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ УҢАЙ ЯККА ХӘЛ ИТӘРГӘ ТЫРЫША, УКУ ЙОРТЫБЫЗДА БАРГАН БЕР ГЕНӘ ЧАРАДАН ДА ЧИТТӘ КАЛМЫЙ. ИҢ МӨҺИМЕ: УЛ ТАТАР СТУДЕНТЛАРЫ ӨЧЕН ЯНЫП ЯШИ.**

✦ *Әнвәр Хуҗиәхмәтов, Психология һәм мәгариф институты профессоры:*

«Дарелфөнүн» – КФУ студентлары, аспирантлары һәм хезмәткәрләре өчен генә түгел, республикабызның барлык татар яшьләре өчен кирәкле газета. Шуңа күрә без аны КФУның база мәктәпләре, гимназияләре, лицейлары укучылары һәм укытучыларына да таратабыз. Профориентация эше белән йөргәндә, Татарстанның төрле район белем бирү йортларында да укучыларга да алып барып житкерәбез, «Дарелфөнүн»дә урын алган язмалар турында бергәләп фикер алышабыз. Республикабыздагы ике теллелек шартларында федераль университетта татар телендә шундый саллы, эчтәлекле татарча гәҗит чыгып килү бик отышлы. Әлеге басма университет, татар студентлары тормышын, аларның киң кырлы эшчәнлеген тулысынча яктырта, дип саныйм. Аның битләрендә фән, укыту процессы, тәрбия эшчәнлеге – һәммәсе турында да мәгълүмат бар. Язмаларда куелган мәсьәләләр киңкырлы, студентларның мәнфәгатьләре дә күз алдында тотыла. Мин аларның һәммәсен хуплыйм. Газетаның бит саннары аз булу гына бераз кәефне төшерә. «Дарелфөнүн» 8 полоса булып чыкса, бик әйбәт булыр иде. Киңәш буларак, шуны җиткерәсем килә: газета битләрендә барлык студентлар да өйрәнә торган фәлсәфә, педагогика, мантыйк, тарих кебек гомуми фәннәр буенча бәйге-олимпиадалар үткәреп, нәтиҗәлелекне тагын да арттырырга мөмкин».

✦ *Васил Гарифуллин, Социаль–фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институтының бүлек мөдире, профессор:*

«Газетаның кечкенә генә түгәрәк датасы белән редакция коллективын да, укучыларны да ихлас котлыйм. Данлы университетыбызның татар телендә чыга торган үз газетасы булуы – куанычлы күренеш. Моннан ике йөз ел элек тә татар телендә газета-журналлар чыгара башлау юлында нәкъ менә университет галимнәре күп көч куйган бит. Димәк, традицияләр уңышлы дәвам итә. Газета тиз арада абруй казанды. Республикабыз журналистларының иң югары бүләге булган «Бәллүр каләм»не яулап алуыгыз – моның нигезле дәлиле. «Дарелфөнүн» – безнең институтыбызның иң якын дусты. Татар журналистикасы бүлегендә укучыларыбызның күпчелеге беренче иҗади адымнарын шушы газетада ясый. Ышанычлы практика базабыз бар дигән сүз бу. Иң зур теләгем: газета озын гомерле булсын иде!»

✦ *Әлфия Юсупова, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге мөдире:*

«Дарелфөнүн» газетасы – бик әһәмиятле газета. Ул студентлар тормышын яктырта торган басма. Шунысы да мөһим: ул татар телендә чыга торган югары уку йорты органы. Бу газетада безнең бүлек студентларының мәкаләләре, шигырьләре, хикәяләре басыла. Шулай ук аның битләрендә университетта эшләгән яисә эшләп киткән галимнәр турында да бик кызыклы мәгълүматлар табып була. Гомумән алганда, анда уку йортыбызда булган вакыйгалар һәрдаим яктыртылып барыла. «Дарелфөнүн»не туган көне белән тәбрик итәбез! Аның 10, 20, 50, 100 еллык юбилейларын үткәрергә насыйп булсын! Аңа озын гомер телибез һәм ул һәрвакыт студентларның яраткан газетасы булып калсын иде!»

✦ *Илһам Фәттахов, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты, филология фәннәре кандидаты:*

Студентлар газетасы «Дарелфөнүн»не яратып карап, укып барам. Аның битләрендә үзебезнең шәкертләр исемен күрүгә күңел сөенә. Газета университет тормышында көн саен була торган вакыйгалар турында оператив рәвештә мәгълүмат биреп баруы белән мөһим. Моңарчы без бу вакыйгалар турында «Казанский университет»тан гына укып белә идек. Әмма татарча фикерләгәч, материалларны туган телдә уку һәм кабул итү күпкә җиңелрәк. Менә бүген дә сезнең газетадан узган атнада безгә кунакка килгән төрек журналисты Әхмәт Яшелтепе белән очрашу турында язылган хәбәрне укыдым. Мин дә Әхмәт әфәнденең «Дарелфөнүн»не «чок гүзәл» газета дип атавы белән тулысынча килешәм. Чыннан да, газетаның эчтәлеге дә, бизәлеше дә бай, игътибарны җәлеп итәрлек. «Дарелфөнүн» битләрендә даими рәвештә студентларыбызның әдәби иҗат җимешләре – шигырьләре, кыска хикәяләре дә басыла. Димәк, укучылар иҗатына зур урын бирелә дигән сүз. Минем калса, бу редакциянең дөрес концепциясе. Гомумән, газета – безнең институт студентлары өчен менә дигән иҗат мәйданы.

Сезне туган көнегез белән котлыйм! Иҗади уңышлар, илһам утыгыз һәрвакыт дөрләп янсын, укучыларыгыз артсын, аудиториягез киңәйсен, тиражыгыз үссен!»

✦ *Резедә Мусина, Фундаменталь медицина һәм биология институты:*

«Газетаны чыга башлаган вакытларыннан ук укыйм. 3 елда газета шактый үзгәрешләр кичерде. Миңа калса, бу үзгәрешләрнең барысы да уңай якка гына булды. Басма форматы, эчтәлеге, темалар төрлелеге ягыннан баеды. Соңгы вакытта «Дарелфөнүн» студентларга тагын да якыная төште. Газета битләре аша мин үзем кебек КФУ студенты булган, нинди дә булса сәләте ярдәмендә уңышка ирешкән яшьтәшләрем турында укып рухланам. Минем дә конкурс-бәйгеләрдә катнашасым килеп китә. «Таныш бул», «Алар бездә укыган», «Дөнья үзебезнеке», «Сәяхәт» сәхифәләрен аеруча яратам. Бүген «Дарелфөнүн»нең даими укучылары, хәбәрчеләре бар. Димәк, ул үз йөзен булдырган, кыйбласын тапкан газета дип әйтергә мөмкин. Туган көне белән котлап, киләчәктә дә бу юлыннан тайпылмыйча, татар студентларына хезмәт итүен дәвам итсен иде».

✦ «Яраткан газетабыз «Дарелфөнүн»гә 3 яшь! Сабый баланың өч яшьлек вакыты – иң татлы, һәрбер күренеш белән кызыксынып, татып карап, дөнья турында күзаллау туплый торган алыштыргысыз күңелле чагы. «Дарелфөнүн» дә сабыйлыкның шул иң татлы өлешен кичерә әле. Без, укучыларның да, аны тизрәк кулга аласы, сабыйны сөйгән кебек итеп, бер генә мәкаләсен дә калдырмыйча, кабат-кабат укып чыгасы, күңелгә илһам, җанга җылы аласыбыз килә. Әлбәттә, яше өчтә генә булса да, «Дарелфөнүн»дә тирән фикерле язмалар, җитди мәкаләләр дә еш урын ала. Уку йортыбыз стеналарында булган иң яңа хәбәрләрне дә безгә нәкъ менә ул җиткерә.

Болардан тыш, «Дарелфөнүн» газетасы – Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары өчен иҗатлары белән уртаклашу, фикердәшләр табу мәйданы да. Аның һәр саны безнең бинада көтелгән кунак, вакытында күреп, алып куярга өлгермәсәң, газетаның яңа саныннан коры каласыңны көт тә тор! Шуңа инде һәр пәнҗешәмбе дәрәҗәле кунакны көткән кебек күңелдә рәхәт бер дулкынлану тирбәлә.

«Дарелфөнүн», сине 3 яшьлек туган көнең белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Киләчәктә дә дәрәҗәңне саклап, иҗади уңышларга төренеп, яңадан-яңа үрләр яулавыңны һәм киләчәк буын укучыларың күңелендә дә лаеклы урын табуыңны телибез! Без сине яратабыз!»

Сиңа мәңге тугры Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары исеменнән
*Лилия Якупова*

✦ *Раил Садретдинов, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:*

«Дарелфөнүн» белән танышу университетка, төгәлрәге, татар журналистикасы бүлегенә укырга кергәч башланды. Күпләр газетаның исемен сәер, диләр, ни аңлатканын белмиләр. әмма газетаның исеме җисеменә туры килеп тора, татарлыгыбызны, төрки дөнья белән бәйләнешне тагын бер кат дәлилли. Иң сөенечлесе: чал тарихлы уку йортыбызда татар телендә газета чыгып килү! Безнең өчен, татар матбугатының яшь көчләре өчен, үзебезне сынап карау мәйданы да. (Әмма күпләр бу мөмкинлекне кулдан ычкындыра). «Дарелфөнүн» – студентлар газетасы! Кайвакыт кирәкле, тозлы-борычлы язмалар да чыккалый. Моннан тыш, газеталарга гына хас булган телне билгеләп үтми мөмкин түгел. Газетада яшьләр сөйләме үзеннән-үзе әдәби тел белән бәйләнеп китә төсле миңа. Үземә килгәндә, газетаның бигрәк тә ахыргы, 4нче битен кызыксынып укыйм. Чөнки бирәдә безнең кебек студентларның иҗаты, аларның тормышны үзләренчә күзаллаулары тәкъдим ителә.

Кыскасы, Туган көнең белән, «Дарелфөнүн»! Теләкләргә килгәндә, рәсмилектән мөмкин кадәр качып, кызыклы мәгълүматка, иҗатка урын күбрәк бирелсен иде! Һәрвакыт шундый яшь булып калырга, яңа иҗади уңышларга ирешеп, канатланырга һәм канатландырырга язсын иде!»

**Илнар ХАҖИЕВ,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

## Яшәсен «Дарелфөнүн»!!!

***«Дарелфөнүн» гәҗите ул***
***Безнең якын дустыбыз.***
***Өч яшь тулды бу ел аңа,***
***Шул уңайдан котлыйбыз.***

***Татар телен үстерүдә***
***Ныклы вузда көчләре.***
***Кызыклы шәп язмалардан,***
***Тулып тора битләре.***

***Өч яшьтә генә булса да,***
***Киң атлый адымнарын.***
***Чиксез могҗизага күмә,***
***Иҗаты мәйданнарын.***

***Студентлар маягы ул,***
***Тормышта олы терәк.***
***«Дарелфөнүн», дию белән,***
***Ашкынып тибә йөрәк.***

***Укытучы өчен дә бит***
***Якын иптәш юк аннан.***
***Яшәешне шатлык били***
***«Дарелфөнүн» туганнан.***

***Бөтен кеше мактый безне,***
***Гөрләп бара эшебез.***
***Иҗат рухы чәчәк ата,***
***Шуңа күрә көчле без.***

***Яшькә карап фикер***
***йөртсәк,***
***Дан казанды бик иртә.***
***Киләчәктә якты мизгел***
***Һәм биек үрләр көтә.***

***Торсын гүзәл бизәкләрдән***
***Иҗатта барыр юллар.***
***Укып чыксаң күңел биреп,***
***Онытыла һәр уйлар.***

***Ике йөз дә ун яшь тула,***
***КФУга бу көздә.***
***Ул кичергән еллар шавын***
***Телик «Дарелфөнүн»гә.***

***Иҗат яктырта каләме,***
***Заманның килер көнен.***
***Яшәсен безнең КФУ,***
***Яшәсен «Дарелфөнүн»!!!***


«МедиаПокорение» бәйгесендә бүләкләү, 2013 ел


«Илһам»чылар белән очрашу, 2012 ел

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.